СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» май 2021г. №1-8

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2020 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №468-ФЗ Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы» нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 декабрендәге №3-43 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (05.06.2018 ел, №6-32, 29.04.2019 ел, №3-41,19.02.2020 ел) карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
1.1. 23 статьяда:
- 4 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга»;
- 5 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2 29 статьяның 5 пункытнда:
- 4 абзацта «капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

- 5 абзацта «капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3 35 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «Блоклы торак төзелеше» кебек җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше», «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «Блоклы торак төзелеше» кебек җир кишәрлекләренен максималь күләме – 5000 кв. м.».

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы И.З.Исмәгыйлевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / И.З.Исмәгыйлев/